**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 11 май № 274

г. Казань

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» еллык республика конкурсын гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» еллык республика конкурсын (алга таба – Республика конкурсы) гамәлгә кую турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмә;

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсының конкурс комиссиясе составы.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү эшен оештырырга.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Республика конкурсын үткәрүне массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 10 май, 274 нче карары белән расланды

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән, полимер продукциясен эшкәртүне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшмәкәрләр һәм юридик затлар арасында милек формасына һәм оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә (алга таба – катнашучылар), Татарстан Республикасында полимер материалларны эшкәртү буенча производстволарны үстерүгә булышлык күрсәтү һәм полимер химиясе өлкәсендә алдынгы фәнни казанышларны популярлаштыру максатларында үткәрелә.

1.2. Конкурс ел саен түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Эшкәртү лидеры» – ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасында җитештерелгән полимер продукциясен эшкәртүнең максималь күләмен күрсәткән катнашучылар арасында;

«Үсеш лидеры» – ел йомгаклары буенча полимер продукциясен эшкәртүнең һәм сәнагать җитештерүе индексы үсешенең иң югары темпларын күрсәткән катнашучылар арасында;

«Инновацияләр лидеры» – инновация эшләнмәләрен гамәлгә кертүне һәм полимер продукциясен эшкәртү тирәнлеген арттыруны гамәлгә ашырган катнашучылар арасында.

Һәр номинациядә бер җинүче билгеләнә.

## 2. Конкурста катнашуга заявкалар тапшыру тәртибе

2.1. Конкурста катнашу өчен дәгъвачылар заявканы электрон рәвештә, барлык битләренә саннар куеп, doc., docx. яки xls., xlsx. форматларында, Times New Roman 14 нче шрифтында, mpt@tatar.ru электрон адресына (e-mail) сайланган номинация нигезендә форма буенча документларны теркәп җибәрә:

«Эшкәртү лидеры» – әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта;

«Үсеш лидеры» – әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта;

«Инновацияләр лидеры» – әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта.

2.2. Заявкаларны кабул итү Конкурс башланган дип игълан ителгән көнгә кадәр 3 ай алдан гамәлгә ашырыла.

Белешмә өчен мәгълүматны (843) 210-05-01, (843) 210-05-03 телефоннары буенча алырга була.

2.3. Заявкаларны карап тикшерү вакыты – заявканы алган көннән соң 20 көн. Конкурс комиссиясе, формасы кушымталарга туры килмәгән документлар тапшырылган очракта, заявканы кире кагырга хокуклы.

3. Конкурсны үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс ел саен үткәрелә.

3.2. Заявкаларны бәяләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты төзи торган конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.3. «Эшкәртү лидеры» номинациясендә Татарстан Республикасында җитештерелгән полимер продукцияне эшкәртү күләме күрсәткечләре буенча катнашучылар рейтингы төзелә. Күләмнең максималь күрсәткече булган катнашучы җиңүче дип танула.

3.4. «Үсеш лидеры» номинациясендә Татарстан Республикасында җитештерелгән полимер продукциясен эшкәртүнең һәм сәнәгать җитештерүе индексы үсешенең темп күрсәткечләре буенча катнашучылар рейтингы төзелә. Сәнәгать продукциясен эшкәртүнең һәм индексы үсешенең иң югары темпларын күрсәткән катнашучы җиңүче дип танула.

3.5. «Инновацияләр лидеры» номинациясендә бәяләү конкурс комиссиясе тарафыннан түбәндәге критерийларның һәрберсе буенча 10 баллы шкала белән башкарыла:

инновацион эшләнмәләрнең шундый ук әйберләр белән чагыштырганда конкурентлы өстенлекләре;

эшләнмәләрнең яңалыгы дәрәҗәсе;

эшләнмәләрнең импортны алыштыру программасына туры килүе.

3.5.1. Конкурс комиссиясе утырышы, әгъзаларының күпчелеге катнашса, хокуклы була.

Конкурс комиссиясе заявкаларны ачык тавыш бирү юлы белән бәяли. Карар тавышларның гади күпчелеге нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

Җиңүче һәр критерий буенча җыелган баллар суммасы нигезендә билгеләнә.

3.6. Конкурс нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче конкурс тәмамланган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә кул куя.

3.7. Конкурста җиңүчеләр турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә аны үткәргәннән соң 15 көн эчендә www.mpt.tatarstan.ru сайтында урнаштырыла.

4. Җиңүчеләрне бүләкләү

4.1. Конкурста һәр номинациядә җиңүчеләр диплом һәм кубок белән бүләкләнә.

Дипломнар һәм кубоклар эшләүгә чыгымнар Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы бюджетында каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.2. Җиңүчеләрне бүләкләү республикада Химик көнен бәйрәм итүгә багышланган чарада яки химия яисә нефть химиясе тармагына багышланган башка тантаналы чарада үткәрелә.

F:\KARAR\2017\274-1.doc

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында «Эшкәртү лидеры» номинациясендә катнашуга
ЗАЯВКА

| | |
|---|---|
| **Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме** | |
| **Предприятиенең юридик адресы** | |
| **Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы)** | |
| **Тел./факс:** | |
| **E-mail:** | |

ПОЛИМЕРЛАРНЫ ЭШКӘРТҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ
(«Эшкәртү лидеры» номинациясе)

| **Чимал маркалары исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Барлыгы эшкәр-телгән** | **Татарстан Республикасында җитештерелгән чимал** | | **Татарстан Республикасыннан читтә җитештерелгән чимал** | | **Импорт** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2016 ел** | **2017 елга план** | **2016 ел** | **2017 елга план** | **2016 ел** | **2017 елга план** |
| 1. Полиэтилен | тонна | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | |
| **Барлыгы** | | | | | | | | |

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

1. Татарстан Республикасыннан читтә сатып алу сәбәпләре турында һәм импорт буенча белешмә.

2. Яңа инвестиция проектын тормышка ашырганда яки эшкәртелә торган полимер материаллар спектрын киңәйткәндә – ирекле формада проект турында белешмә.

| | |
|---|---|
| Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм.<br>Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза. | **Җитәкче**<br>_______________/______________/<br>*имза* *Ф.И.А.ис.*<br>**М.У.** (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) |

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында «Үсеш лидеры» номинациясендә катнашуга
ЗАЯВКА

| | |
|---|---|
| **Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме** | |
| **Предприятиенең юридик адресы** | |
| **Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы)** | |
| **Тел./факс:** | |
| **E-mail:** | |

ПОЛИМЕРЛАРНЫ ЭШКӘРТҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ
(«Үсеш лидеры» номинациясе)

| **Чимал маркалары исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Эшкәртелгән полимерлар** | | | **2016/2015 еллар чагыштырмасы %** | **Сәнәгать җитештерүе индексы** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **2015 ел** | **2016 ел** | **2017 елга план** | | |
| 1. Полиэтилен | тонна | | | | | |
| 2. | | | | | | |
| **Барлыгы** | | | | | | |

Яңа инвестиция проектын тормышка ашырганда яки эшкәртелә торган полимер материаллар спектрын киңәйткәндә, заявкага ирекле формада проект турында белешмә теркәлә.

| | |
|---|---|
| Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм.<br>Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза. | **Җитәкче**<br>_______________/_______________/<br>*имза* *Ф.И.А.ис.*<br>**М.У.** (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) |

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсы турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» конкурсында «Инновацияләр лидеры» номинациясендә катнашуга
ЗАЯВКА

| | |
|---|---|
| **Предприятиенең оештыру-хокукый формасы, предприятиенең тулы исеме** | |
| **Предприятиенең юридик адресы** | |
| **Элемтәгә керү өчен зат (конкурста катнашуга җаваплы)** | |
| **Тел./факс:** | |
| **E-mail:** | |

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

1. Техник тасвирлама һәм куллану өлкәсе белән продукт турында белешмә (шундый ук продуктлар белән чагыштырганда конкурентлы өстенлекләре; яңалык дәрәҗәсе; импортны алыштыру программасына туры килү).
2. Инновация продуктын гамәлгә керткәндә килеп чыккан финанс-икътисадый нәтиҗә.
3. Өстәмә материаллар (гариза бирүче ихтыярына).

| | |
|---|---|
| Әлеге заявка белән конкурста катнашуыбызны раслыйм.<br>Конкурс турында нигезләмә һәм катнашу шартлары белән риза. | **Җитәкче**<br>_______________/_______________/<br>*имза* *Ф.И.А.ис.*<br>**М.У.** (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда) |

_______________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 10 май, 274 нче карары белән расланды

«Татарстан Республикасында полимер продукциясен эшкәртү өлкәсендә лидер» республика конкурсының конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, конкурс комиссиясе рәисе |
| Сабиров Ринат Касыйм улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сикорский Руслан Викторович | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының химия һәм газ химиясе бүлеге мөдире, комиссия секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Бикморзин Азат Шәүкәт улы | «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Дьяконов Герман Сергеевич | Казан милли тикшеренү технология университеты ректоры (килешү буенча) |
| Миңнеголов Фәрит Герт улы | «Казаньоргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Савельчев Алексей Петрович | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы урынбасары |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвест-холдинг» (килешү буенча) ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры. |

F:\KARAR\2017\274_2.doc